ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эш йомгаклары турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының эш йомгаклары турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмметшин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлегенең уңай тәҗрибәсен түбәндәге өлешләрдә билгеләп үтәргә:

парламент контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары эшчәнлеген камилләштерүдә;

парламент эшчәнлегенең гражданнар өчен ачык булуында;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты эшен активлаштыруда.

3. Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына тәкъдим итәргә:

3.1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы комитетлары һәм Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары белән бергә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында тәкъдим итү һәм алар буенча эшләүне дәвам итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары эше тәҗрибәсен киңәйтергә.

3.3. Сайлаучылар наказлары һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне, шул исәптән аларны кирәк булганда федераль программаларга кертү буенча, көчәйтергә.

3.4. Татарстан Республикасында, беркетелгән сайлау округларында уздырыла торган чараларда катнашу тәҗрибәсен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары каршындагы яшьләр парламентлары белән эшләүне активлаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2605-VI ДС